**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ
РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
“_15_” _май_ 2024 ел.

КАРАР
№ _230_

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 14.09.2022 № 135 карары белән раслаган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында” гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карары нигезендә «Бюджет өлкәсендә хезмәткә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмаган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен арттыру турында һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәткә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәткә түләү шартлары турында» 30.03.2018 ел, № 195 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатыннан, Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 14.09.2022 № 135 карары белән раслаган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында” гы нигезләмәгә (18.11.2022 елгы №145, 27.01.2023 елгы 165 үзгәрешләр белән) түбәндәге төзәтмәләр кертергә:

1.1. 1нче пунктның 4нче абзацында “12688,0” саннарын “13323,0” саннары белән алыштырырга;

1.2. 3нче пунктнын 3нче пунктчасында «15 процент» сузләрен «37 процент» сузләренә алыштырырга;

1.3. 7нче пунктнын 4нче пунктчасында «15 процент» сузләрен «37 процент» сузләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе: Г. Г. Хәкимов